СОВЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2022 елның 14 декабре № 23/5

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Аксу авыл җирлегенең Генераль планын раслау турында

«ГК-групп» ҖЧҖ тәкъдим иткән Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Аксу авыл җирлеге Генераль план материалларын карап, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Зур Аксу авыл җирлеге Генераль планы проекты буенча 2022 елның 12 декабрендәге гавами тыңлаулар беркетмәсен һәм 2022 елның 13 декабрендәге гавами тыңлаулар бәяләмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 7 һәм 29 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Аксу авыл җирлегенең Генераль планын электрон чыганактагы кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетына территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында (https://fgistp.economy.gov.ru) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Зур Аксу авыл җирлегенең Генераль планын урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтындагы (www.droganoye.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Зур Аксу авыл җирлеге бүлегендә бастырып чыгарырга.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы Башлыгы, Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе М.Р. Гафаров